ISSN 0868-4545



Салават күпере

2008 ел —
Гаилә елы

Иң кадерле кеше

Җир йөзендә иң кадерле кеше – әни. Ул безне тудырган, тәрбияләп үстергән, белем алырга мөмкинлек биргән кеше. Мин тормышымны әнидән башка бер генә мизгелгә дә күз алдына китерә алмыйм. Әнием өчен мин – бердәнбер кыз, ә ул минем өчен – бердәнбер сөекле әни. Ул эшкә киткәч, мин моңсуланам, аның тизрәк эштән кайтканын түземсезләнеп көтәм. Миңа аның иртә белән уятканда, кызым дип түгел, ә йолдызым дип дәшүе бик ошый. Әниемнең кабарып торган, йомшак, җылы кабартмаларын авыз итсәң, телеңне йотарлык – бик тәмле, искиткеч! Куллары да бер генә дә тик тормый, әле оекбаш, әле кофталар бәйли. Ул бәйләгән оекбашны кисәң, аякларың беркайчан туңмас – авыртмас. Менә шундый ул – дөньядагы иң яхшы кешеләрнең берсе булган әнием!

Инзилә ГАРИФУЛЛИНА, 14 яшь.
Балтач, Куныр.

Әтине яратам

Әтинең туган көненә
Ясадым бүләк үзем.
Көтәмен эштән кайтканын,
Тәрәздән алмый күзем.

Әтиемне мин яратам,
Ул да мине ярата.
Эштән кайткан чакта ул да
Күчтәнәч алып кайта.

Миләүшә МИҢЛЕБАЕВА, 13 яшь.
Казан, 5 нче гимназия.



Дәминә ГЫЙБАДУЛЛИНА, 7 яшь.
Казан, 77 нче балалар бакчасы.



Илсаф ӘХМӘТШИН, 8 яшь. Әлки, Татар Борнае.



Наташа ШЕРДАКОВА, 6 яшь.



Женя ТУРКИНА, 7 яшь.

Бөгелмә шәһәрендәге 14 нче «Торнакай» балалар үсеше үзәгенә йөрүче сабыйларның рәсемнәрен тәкъдим итәбез.



Арина ЗВЯГИНЦЕВА, 5 яшь.

Әнигә бүләк

Яз белән бергә көтәм
Мин әниләр бәйрәмен.
Бүләк итәсем килә
Әнигә гөл бәйләмен.

Тик гөлләр уянмаган,
Бакчаларда кар әле.
Чәчәкләрнең атканын
Көтәселәр бар әле.

Шуңа күрә кәгазьдән
Ясыйм язның гөлләрен.
Алар ошар әниемә,
Күтәрер күңелләрен.

Айгөл САДРИЕВА, 15 яшь.
Казан, 5 нче гимназия.



Лена КОЗИОНОВА, 6 яшь.



Даша ЕФИМОВА, 4 яшь.

Игтибар! Бәйге дәвам итә!

Шүрәле малае Шүркә



Татлы хыял

Бара торгач, Шамил бер матур аланга килеп чыккан. Шул алан уртасында Шүркә китап укып утыра икән. Утырган агачы да гади түгел, Габдулла Тукай әкиятендәге бүрәнә. Шамил Шүркәне күрүгә татлы хыялга бирелгән, менә ул авылга Шүрәле малаен тотып алып кайта, бер мөгезеннән өстери, бер койрыгыннан тарта... Шулчак ул Шүркә янына килеп җиткәнен сизми дә калган. Бу вакытта Шүркә, Шамилне күреп, койрыгын бүрәнә ярыгына тыгып куйган. Шамил килеп тә җиткән, Шүркәне мөгезеннән эләктереп, авылга таба өстери дә башлаган. Ләкин бүрәнә авыр булганлыктан, берни дә барып чыкмаган. Шүркә шунда хәйләгә керешкән: «Койрыкны бүрәнә ярыгыннан алырга булышсаң, мин үзем дә сиңа иярәчәкмен», – дигән.

Шамилнең татлы хыялы, бармаклары бүрәнә ярыгына кысылгач, челпәрәмә килгән. Шүркә аңа шунда Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкиятен сузган. «Бармакларыңны ярыктан аласың килсә, менә шушы әкиятне укы», – дигән. Шамилгә әкиятне теләсә дә, теләмәсә дә, укып чыгарга туры килгән. Шунда гына ул үзенең нинди зур ялгышлык эшләгәнен аңлаган. Тырышып укырга сүз биргән. Шуннан соң алар чын дуслар булып киткәннәр.

Диана ХАҖИЕВА, 10 яшь.
Мамадыш, 2 нче урта мәктәп.

Шамилнең бабасы – Былтыр?!

Шулай итеп, Шамил урманга киткән. Барса, Шүркә компьютер артына утырган да, аннан «Шүрәле» әкиятенә ясалган иллюстрацияләрне күрсәтә-күрсәтә, энеләренә шушы әкиятне сөйләп тора икән.

Шамил Шүркәгә:

– Әй, Шүрәле актыгы, нәрсә эшлисез анда? Күрсәт миңа да! – дип кычкырган.

Шүркә компьютердагы рәсемнәрне бу тәртипсез малайга да күрсәтеп чыккан.

– Кара әле, нишләп минем бабай синең бу әрҗәнә кереп утырган? Бу бит бабайның яшь чагы, мин беләм, фотоальбомда күргәнем бар минем! – дигән Шамил.

– Нишләп алай дисең? Синең «Шүрәле»не дә укыганың юк мәллә? Юк, синең бабаң түгел, бу – Былтыр! – дигән Шүркә.

Шамилгә, кызарып, башын аска июдән башка чара калмый.

– Ә менә бусы – мөгезлесе, чыннан да, минем бабам. Быел аңа 100 яшь тулды. Урманда саф һава сулап яшәгәнгә күрә шундый озын гомерле булды ул! Бабам гомер буе кешеләр белән аралашырга теләп яшәде, тик алар гына аңламады аны. Әнә бит, син бабам дип атаган Былтыр аның бармагын бүрәнәгә кыстырган! Ни явызлык кылгандыр минем бабам? Ул бит уйнарга гына теләгән! Ярар, бармак төзәлгән дә, ди, тик бөтен Шүрәле ыруы алдында оятка калуын гына әйт син! Җир убылса, җир астына төшеп китәрлек, билләһи!

Шүркәне тыңлаганнан соң, Шамил уйга кала. Ул Шүрәле малаеның кирәген бирәм, дигән уеннан кире кайта.

Регина МӨХЕТДИНОВА, 9 яшь (рәсеме дә аныкы).
Чүпрәле районы, Иске Чүпрәле.







Рашат НИЗАМИ

Кем

Хуҗалары, маңгаендагы тир тамчыларын сөртте дә, чәй эчәргә өенә кереп китте. Ике дус – пычкы белән балта, кояш кызуыннан качып, күләгәгә кыңгыр яттылар. Эш юклыктан гәп куертып җибәрделәр.

– Кара әле, дускай, – диде пычкы, энҗе тешләрен елтыратып. Мин булмасам, бу тәпәндәй юан агачларны син ничек кисәр идең. Мин сиңа караганда кирәклерәк бит хуҗабызга. Миннән башка яши алмас иде ул, мөгаен.

Пычкының болай мактануы балтаның кәефен кырды. Аның сер бирәсе килмәде:

– Ә-ә, шулаймыни. Алайса, син менә бу колач җитмәслек тумраннарны ярып кара! Күпме маташсаң да булмый ул синнән. Димәк, мин сиңа караганда кирәклерәк.

– Юк, мин кирәклерәк!

– Юк, мин...

Балта белән пычкы, бәхәсләшә торгач, бер-берсенең якасына ябыштылар. Болай итеп тә җиңүче табылмагач, пычкы балтага әйтеп салды:

– Йә, алайса, әнә теге бүрәнәне

Кирәклерәк

урталай өзеп чыгар. Шуннан соң белербез, кемнең кем икәнен.

Әй кереште балта чапкаларга – тирә-якка йомычкалар гына оча. Киерелеп ала да әле бу яктан, әле теге яктан китереп суга. Маңгаена борчак тирләр бәреп чыкты мескеннең. Әй селтәнде балта, әй тырышты, ләкин юкка. Юан бүрәнә бары тик чокырланып кына калды. Шулай да хур буласы килмәде:

– Үзең әнә теге тумранны ярып кара әле, булдырырсың микән?

Хәзер инде пычкы эшкә кереште. Тирә-якка зеңләгән тавыш кына тарала. Озын гәүдәсе белән киерелеп ала да, тумран уртасына чаба. Чү, ни булды!

Пычкы, чыраен сытып, күзләрен йомды. Менә сиңа мә – урт теше сынып чыккан бит. Имән агачы таш кебек каты, таза шул ул.

...Пычкы белән балта яңадан күләгәгә сузылып яттылар. «Үз урынында һәркайсыбыз кирәкле икән»,– дип кабатлады яңагы бәйләнгән пычкы, дустын кочаклап.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



«Бишле»ләр илен...

4 1+1+1+1+1= ...

3 **Сүзләрне татарчага тәрҗемә ит**

а) воспитательница
б) детский садик
в) друг










5 **Дәвам ит.**


а) Сыер сөт бирә.
б) Ат...
в) Сарык ...

2 5+1 = ...



1 **Алма нинди төсләрдә була?**

а)
б)
в)









6 **Сорауларга җавап тап.**
а) Әтиеңнең әнисе сиңа кем була?
б) Әниеңнең әтисе кем була?

7 **Хаталарны төзәт.**
а) Сфетофорның 6 күзе бар.
б) Сыерның аяклары өчәү була.
в) Әтәчнең кикриге койрыгында була.

8 **Хаталарны төзәт.**
а) Кич җиткәч, Ай батты.
б) Ике бака очып бара.
в) Ала карганың өченче аягы аксак иде.

9 **10га кадәр санауда кайсы саннар төшеп калган:**
1, 3, 5, 6, 8, 10

10 Менә син «бишле»ләр илендә. Хәзер әби-бабаңа кунакка да бара аласың. Алар сине коймак белән сыйлар.

Зиннур ХӨСНИЯР

Рәссам Диләрә НӘУРУЗОВА





– Күзләреңне йомдың, апа,
Курыктыңмы әллә, дим?!
Арыслан дип уйлый күрмә,
Энең Марсель генә мин!
Балтач, Таузар.

Айзирәк, 12 яшь
Марсель, 3 яшь 5 ай

Рәмис, 1 яшь 1 ай





– Алло! Әйе, бу мин – Рәмис!
Эшләрем тыгыз әле...
Казлар саклыйм! Кичен кабат
Шылтыратыгыз әле...
Кукмара, Вахит.




Эльвир, 7 ай
Алия, 6 ай

– Күрше кызыбыз Алия
Көн дә кунакка керә.
Ул керүгә, Эльвир аны
Шундук үбеп өлгерә!
Ютазы, Бәйрәкә.

– Ак боланга утырып,
Кар-бураннар туздырып,
Азат китте еракка –
Көньякка... юк!.. Төньякка!
Кама Тамагы, Келәнче.

Азат, 2 яшь 2 ай




Энҗе, 6 яшь




– Йокыдан тордым да
Сурәткә төштем мин:
Күрәсезме мине –
Нинди зур үстем мин!
Биектау, Алан.



Даниф, 4 яшь

– Күрәсезме, шар ачык
Икебезнең дә авыз.
Кайсыбызныкы бик зур? –
Йәгез, әйтеп карагыз.

Арча, Утар Аты.



Алинә, 6 яшь

– Артистка буламын, диеп,
Җан атып йөргән чагым.
Талант та бар, чибәрлек тә –
Ни кирәк инде тагын?

Чистай, Нарат-Елга.



Динә, 6 яшь Диләрә, 4 яшь



– Без көләбез рәхәтләнеп,
Әйдә, сез дә көлегез!
Елмаеп һәм көлеп үтсен
Сезнең һәрбер көнегез.


Теләче, Алан.



Илсинә, 11 ай

– Тагын тиргәрләр инде –
Астымны юешләдем.
Юешләмәс идем дә –
Чәй эчү килешмәде.

Балтач, Алан.



Риназ, 6 яшь 7 ай



– Бик тыйнак күренәм бугай мин –
Оялчан ук түгел болай мин:
Йөзләрем, күзләрем ут яна,
Мин – шаян, мин – зирәк, мут бала!

Казан.



Рәхмәт



Барысы да гап-гади күзлектән башланды.

– И-и... бигрәк хәтерсез инде башкаем. Гәзит укырмын дигән идем... Кая гына куйдым шул күзлегемне? Инсаф балам, син белмисеңме?

Әбисенең шулай дип дәшүе булды, Инсаф җәһәт кенә күзлекне табып та бирде.

– Син тапмасаң, көне буе эзлисе идем мин бу күзлекне. Рәхмәт, балам! – дип әбисе. Инсафның башыннан сыйпады.

Инсаф бер башка үсеп киткәндәй булды. Рәхмәт ишетүе рәхәт икән!

Әнисе, өчпочмак пешерү өчен дип, камыр җәя иде. Малай аның янына килде дә:

– Әни, син дә берәр әйбереңне югалтмадыңмы? – дип сорады.

– Юк шул, Инсаф улым, югалтмадым... Ә нигә алай дип сорыйсы иттең әле? – диде әнисе.

– Болай гына, – диде Инсаф. Бераздан:

– Әни, әгәр югалтсаң, әйт, яме! Бик тиз табып бирермен... – дип әйтеп куйды.

– Шулай итәрмен, улым... Бер-бер әйбер югалтсам, сиңа әйтермен! Карале, әллә миңа булышасыңмы? Җаемнәргә менә бу итле бәрәңгеләрне салып тор әле, улым...

Рәссам Диләрә НӘУРУЗОВА

Ләбиб ЛЕРОН



ишетү рәхәт

Икәүләп эшләгәч, өчпочмаклар бик тиз әзер булды.

– Син булышкач, өчпочмаклар тагын да тәмлерәк була инде хәзер... Рәхмәт, улым! – диде әнисе.

Рәхмәт ишетүе рәхәт шул! Инсаф янә дәү булып үскәндәй тойды үзен.

Ул көнне бик күп рәхмәт ишетте ул. Әтисеннән дә, бабасыннан да, апасыннан да. Инде Инсаф чыннан да дәү булып үсте. Эшне рәхмәт өчен генә түгел, ә бәлки болай гына да, үзең теләп тә эшләргә була икәнен белә ул хәзер.



Кадерле дускай?

Сиңа да рәхмәт ишетүе рәхәтме?

Өлкәннәргә, иптәшләреңә, энесеңелләреңә нинди игелекле эшләр эшләгәнең бар? Ул эшләрне рәхмәт өчен генә эшләмисеңдер бит? Безгә кызыклы хатлар, шигырьләр язып җибәр, яме?



«Йолдызлы басу»



«Салават күпере»нең алдагы саннарының берсендә (№ 11 (212), 2007 ел) шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның «Йолдызлы басу» дигән шигъри әсәреннән бер өзек бастырган идек. Шул өзектән соң: «Туган ягыгыздагы болын-кырларның, басуларның, елга-суларның, тау-чокырларның... нинди исем-атамалары бар? Шулар турында кызыклы хат язып җибәр!» – дигән идек. Журналханәгә килгән берничә хат белән сине дә таныштырасы иттек, дускай.

Әлеге хатларның авторларына, шулай ук, редакциягә иң беренчеләрдән булып хат юллаган Азнакай һәм Чистай кызлары Алсу Гарифуллина белән Миләүшәгә (ни кызганыч, Миләүшә фамилиясен язарга онытткан, шөкер – адресы бар), вәгъдә ителгәнчә, шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның култамгасы белән китаплар җибәрелә.

Мәгъфурҗан чишмәсе

Авылым яныннан Калмыя елгасы ага. Калмыяга берничә чишмә кушыла. Шул чишмәләр арасында иң зурысы, әбиләр әйткәнчә, иң тәмле чәй чыгара торганы – Шифа чишмәсе.

Тагын Фиршат чишмәсе бар. Ул Калмыяның сул як ярында Нәҗми чокырына каршы урнашкан. Бу чишмә бер югала, бер барлыкка килә.

Безнең авыл тауларга, күлләргә, яланнарга бик бай. Шуларның берсе – Үрдәк күле яланы. Ул печәне, җиләге, төрле дару үләннәре белән халыкны кинәндерә.

Әндереш ягында Мәрфуга яланы бар. Ул һәркемне җиләге белән сөендерә.

Сөякәй ягындагы Мулла куагы яланында печән чабалар.

Дусайга китә торган басу юлыннан уңдарак Хисмәкәй күле урнашкан. Элегрәк бик зур булган. Анда әрәмәлек, сазлык үләннәре, казаяк үләне, камыш, тал күп үскән. Хәзерге вакытта күләме кечерәйде, тирә-юне киптерелде һәм басуга кушылды. Хисмәкәй күле матур табигатьле һәм ничектер серле урын.

Без ял итәргә, табигать белән танышырга Кала тавына барабыз. Анда нарат, чыршы, каен, имән, усак, карама, юкә, шомырт, чикләвек агачлары үсә. Адаштыра торган урыннары күп булганга күрә, кешеләр һәр тау битенә, һәр җиргә төрле-төрле исемнәр биргәннәр. Аеруча адаштыра торган урыннарын Җенле тау, Чия тавы дип атаганнар.

Авылның горурлыгы булып Тирән чокыр тора. Тирән чокыр безне җиләкләре белән сыйлый, авылның бик күп кешесен кышлык печән белән тәэмин итә, көз һәм яз айларында анда авыл көтүе йөри.

2007 елның җәендә минем бабам бер чишмәнең җир өстенә бәреп чыкканын күргән. Ул аны балчыктан, чүптән арындырып чистарткан. Зур агач тәпән алып барып, яхшылап урнаштырган. Җәй буе бабам һәм тирә-як күршеләр шул чишмәнең суын эчтеләр. Мин дә ул чишмәнең суын эчтем. Бигрәк тәмле шул чишмә суы! Бабам исеме белән мин аны Мәгъфурҗан чишмәсе дип атадым.

Ралина ХАННАНОВА, 12 яшь.
Мөслим, Октябрь.

Таузар чишмәләре

Безнең районыбыз урман-кырларга, чишмәләргә, елга-күлләргә бик бай. Таузарда да чишмәләр күп. Шуларның берсе «Илдар чишмәсе» дип атала. Ул Таузардан Кенә авылына менә торган юл кырыенда. Чишмәне Кенәгә эшкә менгәндә Илдар Гариф улы таба. Тагын бер чишмә бар. Анысын «Кызыл чишмә» дип йөртәбез. Өченче чишмәбез – «Тау буе чишмәсе». Аның суын авыл халкы аеруча яратып эчә.

Авылыбызда бик матур бер күл дә бар. Аны «Альберт күле» дип йөртәләр.

Безнең авылны кечкенә генә таулар уратып алган. Авылыбызны башта «Таулар иле» дип атаган булганнар. Авылыбыз эчендә зур булмаган тау бар. Аны «Тәкәрлек» дип атыйлар. Бу тау Кенәгә менә торган олы юл белән авыл эчендәге юл арасында урнашкан.

Авылыбызның икенче ягында – «Шубан таулары». Шушы таулар яныннан гына Шушма елгасы ага. Аңа инеш кушыла. Инеш авылның уртасыннан ага.

Айзирәк СИТДЫЙКОВА, 13 яшь.
Балтач, Таузар.



Алсу СӘЙФУЛЛИНА, 8 яшь.
Нурлат, Якты Күл.



Фәнилә ФӘЙЗУЛЛИНА, 12 яшь.
Әлки, Урта Әлки.



Иштирәк – гүзәл авыл

Исәнмесез, «Салават күпере» журналы хезмәткәрләре! Без, ягъни Тукай районы Иштирәк урта мәктәбенең V сыйныф укучылары (сыйныф җитәкчесе – Рима Галимҗан кызы Ризатдинова), сезгә үзебезнең эшебезне җибәрергә уйладык әле. Безнең сыйныфта өч кенә укучы укый (мәктәптә дә алтмыш кына бала). Тарих түгәрәгендә авылыбыз тарихын һәм исем-атамаларын да өйрәнәбез.

Безнең Иштирәк авылы Тукай районының гүзәл җирендә урнашкан. Исеме дә авылыбызның матурлыгы турында сөйлидер кебек. Атамалар, авыл табигате белән нык бәйләнгән. Атамалар хакында шигырь юллары белән әйтергә булдык.

Авылыбыз гүзәл җирдә –
Үсә тирәк, таллары...
Кайда барсак, сагындыра
Урман-суы, таулары.
Аулаш чишмәсе кушыла
Наратбаш елгасына.
Кыргыз очыннан менәсең
Сарыкбаш сазлыгына.
Казлар тезелеп йөзәләр
Ишкәй күле өстеннән.
Үрдәкләр нидер йоталар
Әхли күле төбеннән.

Алан күле сыенып тора
Унберле басуына.
Шул басулардан төшәсең
Арслан сазлыгына.
Керәч тавыннан башлана
«Энҗе-Флүр» чишмәсе.
Атау суларын эчмибез –
Килми анда төшәсе.
Маша тавыннан карасаң,
Күренә Тунгыч буасы.
Балчыклы урманы буйлап
Барасы да барасы...

Регина КАШАПОВА,
Анжела МИҢЛЕБАЕВА,
Айрат МИҢЛЕБАЕВ.



А. ГАЙФУЛЛИН, 11 яшь.
Әлки, Урта Әлки.



Фәридә МӨХТАРОВА, 8 яшь.
Кукмара.



Чулпан ШАКИРОВА, 7 яшь.
Кукмара, 4 нче мәктәп.



Алисә ШӘЙХЕТДИНОВА, 7 яшь.
Балык Бистәсе, Кече Әшнәк.



Энҗе ГАРИПОВА, 8 яшь.
Биектау, Айбаш.



Әдилә МӨХӘММӘТШИНА, 7 яшь.
Кукмара, 4 нче мәктәп.



Динар ИСМӘГЫЙЛЕВ, 5 яшь.
Азнакай.



Инсаф БИКМӘТОВ, 7 яшь.
Балык Бистәсе, Кече Әшнәк.



ИНГЛИЗЧӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛ





What is it? – Нәрсә бу?
It is a cabbage. – Бу – кәбестә.
What is it? – Нәрсә бу?
It is a potato. – Бу – бәрәңге.

Cabbage [кэ'бидж] – кәбестә.

Potato [потэ'йтоу] – бәрәңге.

Green [грин] – яшел.

What is it? – Нәрсә бу?
It is a cucumber. – Бу – кыяр.
What colour is the cucumber? – Бу кыяр нинди төстә?
The cucumber is green. – Кыяр яшел төстә.

Cucumber [кью'камбэ] – кыяр.





Banana [бэна'на] – банан.





Cherry [че'ри] – чия.

Lemon [лэ'мон] – лимон.

Colour [ка'ла] – төс.
Yellow [у'лоу] – сары.
Red [рэд] – кызыл.

What is it? – Нәрсә бу?
It is a banana. – Бу – банан.
What colour is it? – Ул нинди төстә?
It is yellow. – Ул сары.
What colour is the cherry? – Чия нинди төстә?
The cherry is red. – Чия кызыл.

No [но'у] – юк.
Don't like [до'унт лайк] – яратмыйм.

What is it? – Нәрсә бу?
It is a lemon. – Бу – лимон.
Do you like lemon? – Син лимон яратасыңмы?
No, I don't like lemon. – Юк, мин лимон яратмыйм.

ЗИЛӘ рәсемнәре

Хрустальный конек

«Хрустальный конек» («Бәллүр тимераяк») – тимераякта фигуралы шуу серләренә өйрәтү, спорт-сәламәтләндерү мәктәбе.
Бездә балалар да, олылар да шөгыльләнә ала.
Дәресләр атнага өч тапкыр, сезгә уңайлы вакытта уздырыла.





Безнең адрес:
Казанда – «Татнефть Арена» һәм «Ак бүре» спорт сарайлары.
Тел.: (843) 570-51-60, 89173943003.
Алабуга һәм Яшел Үзән шәһәрләрендә – җирле «Боз сарайлары».
Тел.: 89172697000.

Рәхим итегез!







Сәләват күпере

3(216) — 2008



ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ: «ТАТМЕДИА» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ.
Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛЬ: ОАО «ТАТМЕДИА».
Журнал основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Иван ВОРОБЬЕВ рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г.Казань, ул.Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

«Идел-Пресс» ААҖ.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
Производствога бирелде 14.03.2008 ел.
Басарга кул куелды 14.03.2008 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 11679 данә. Заказ Т-265.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Яз килә

*Бөре булып борын төртә-төртә,
Яңгыр булып тәрәз чиртә-чиртә,
Җиләс җилләр булып исә-исә,
Назлы кояш булып балкый-балкый,
Умырзая булып көлә-көлә,
Күрәсезме, җиргә яз килә!*

